Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Шәһәр тибындагы Җәлил поселогы башкарма комитеты

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
18.02.2022 ел №7

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Кызыл Бакча торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Кызыл Бакча авылы гражданнар җыенында кабул ителгән карарларны тормышка ашыру максатларында «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставы белән, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогыбашкарма комитеты карар бирә:

1. Кушымта итеп бирелә торган «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Кызыл Бакча торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын җыю» тәртипне расларга (1 нче кушымта).
2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Сарман муниципаль районы
Җәлилшәһәртибындагыпоселогы
башкарма комитеты җитәкчесе И.Ф. Галлямов

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Җәлилшәһәртибындагыпоселогы
башкарма комитеты җитәкчесенең
2022 елның 18 февраль
7 номерлы карарына 1 кушымта

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кызыл Бакча авылы
Торак пунктта гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1. Сарман муниципаль районының Кызыл Бакча торак пунктында (алга таба - авыл җирлеге) гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен әлеге тәртип билгели.

2. Гражданнарның үзара салымы түләү, гражданнар җыенында катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләренә карамастан, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Кызыл Бакча торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар 2022 елның 31 мартына кадәр, халык саны җирлектә яшәүчеләрнең гомуми санынннан 30 проценттан артмый торган аерым категорияләреннән тыш башкарыла.

3. Түбәндәге категория гражданнар үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:

а) өлкән яшьтәге гражданнар (80 яшьтән өлкәнрәкләр);

б) I һәм II төркем инвалидлар;

в) җирлек территориясендә ел дәвамында яшәмәүче гражданнар (көндезге уку формасы студентлары; РФ Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүче затлар; хөкем ителгәннәр h. б.);

г) тормыш авыр хәлдә калган гаилә әгъзалары (СОП, янгын сүндерүчеләр, авыр авыручылар h. б.);

4. Бер тапкыр түләү турында белдерү (квитанция) бланкы гражданнарга Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында халыкка хәбәр итү юлы белән, шулай ук кул кушырып тапшыру яисә почта элемтәсе аша юллау юлы белән җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (квитанциядә) гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, бер тапкыр бирелә торган түләү суммасы, аны түләү вакыты булырга тиеш.

5. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акча Татарстан Республикасы буенча ФКХИ (Сарман муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы) шәхси счетына керә.

6. Түләүләр физик затлар кушуы буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган оешма аша, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы

аша, сылтама буенча, почта күчерүләрен (исәп-хисап оешмалары) тормышка ашыру юлы белән башкарыла. https://uslugi.tatarstan.ru/

7. Чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар, квитанция түләү фактын раслый.

8. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән гражданнарның үзара салымы акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Җәлил шәһәр тибындагы поселогы
башкарма комитеты җитәкчесенең
2022 елның 18 февраль
7 номерлы карарына 2 кушымта

«Җәлил шәһәр тибындагы поселогы»
муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында белдерү (квитанция)

| | |
|---|---|
| **Извещение**<br><br>**Кассир** | **Получатель:** Управление федерального казначейства по РТ (Финансово-бюджетная палата Сармановского муниципального района)<br>**ИНН:**1636005341<br>**КПП:**163601001<br>**ОКТМО:**92653155<br>**Банк:** отделение –НБ Республики Татарстан Банка России//УФК по Республике Татарстан г.Казань<br>**БИК:**019205400<br>Единый казначейский счет: 40102810445370000079<br>Казначейский счет: 03100643000000011100<br>**л/счет:**04113000630<br>**Код администратора дохода:**891<br>**КБК:** 89111714030130000150 Средства самообложения граждан, зачисляемые в бюджеты городских поселений<br>Плательщик ФИО:____________________<br>Адрес плательщика:____________________<br>ИНН плательщика:____________________<br>Сумма:____________руб.________коп.<br>Плательщик (подпись):____________________ |
| **Квитанция**<br><br>**Кассир** | **Получатель:** Управление федерального казначейства по РТ (Финансово-бюджетная палата Сармановского муниципального района)<br>**ИНН:**1636005341<br>**КПП:**163601001<br>**ОКТМО:**92653155<br>**Банк:** отделение –НБ Республики Татарстан Банка России//УФК по Республике Татарстан г.Казань<br>**БИК:**019205400<br>**Единый казначейский счет:** 40102810445370000079<br>**Казначейский счет**: 03100643000000011100<br>**л/счет:**04113000630<br>**Код администратора дохода:**891<br>**КБК:** 89111714030130000150 Средства самообложения граждан, зачисляемые в бюджеты городских поселений<br>Плательщик ФИО:____________________<br>Адрес плательщика:____________________<br>ИНН плательщика:____________________<br>Сумма:____________руб.________коп.<br>Плательщик (подпись):____________________ |